Мәмәшир авыл җирлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында

02.03.2026

Гавами тыңлаулар үткәрү урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир ав., Яшьләр ур., 29Б (Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).

Гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты: 2 март, 2026 ел. 09 сәг. 00 мин.

Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

Гавами тыңлаулар уздыру өчен нигез: «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәмәшир авыл җирлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында» Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгының 2026 елның 11 февралендәге 1 номерлы карары

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәләнең исеме: Мәмәшир авыл җирлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү

Гавами тыңлаулар турында халыкка хәбәр итү: гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмати хәбәр (Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгының 2026 елның 11 февралендәге 1 номерлы карары):

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Мәмәшир авылы торак пункты территориясендә, Яшьләр урамы, 29Б йортта урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гавами тыңлауларда катнашучылар саны турында белешмәләр: 36 кеше.

Гавами тыңлауларда каралган мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә яшәүчеләрдән язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде:

1. Мәмәшир авыл җирлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү буенча мәсьәләне хупларга.
2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советына Мәмәшир авыл җирлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерүгә халыкның ризалыгын белдерүне тәкъдим итәргә.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Мәмәшир авылы торак пункты территориясендә

Яшьләр ур., 29Б й. урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г. Әхмәтҗанов

СОВЕТ МАМАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ •
ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702